# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«19» 11 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5184

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ак каен» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ак каен» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ак каен» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Р. Хәбибуллин

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «19» 11 5184 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ак каен» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | « Мәктәпкә сукмак» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Развивайка» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе - «Ак каен»
балалар бакчасы мөдире _______________ Э.Н. Мортазина

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә
хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ
җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ак каен» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Мәктәпкә сукмак»** - программа балаларның мәктәптә уңышлы укуга әзерләүгә, өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларны мәктәп укулары ситуациясенә уңышлы яраклаштыру өчен социаль-психологик шартлар тудыруга (мәктәп дезадаптациясен профилактикалауга) юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә, кабинетның мәйданы 50 кв.м, балалар саны - 16.

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

2. **«Развивайка»** - программа шәхесне, аның иҗади потенциалын, иҗади сәләтләрен, балаларның әхлакый-эстетик үсешен үстерүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (10 тәрбияләнүче).

Дәресләр атнага бер тапкыр үткәрелә.

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе - «Ак каен»
балалар бакчасы мөдире ____________________ Э.Н. Мортазина